## ***Исәнмесез.***

*Йөз чөереп йөрү кешелекме?*

*Сәлам биреп уз син кешегә!*

*Ачык йөзе, җылы сүзе белән*

*Җирдә кеше зур да, көчле дә.*

*Исәнмесез! Күрешә материклар,*

*Якынлаша җирнең уллары;*

*Шиңмәсенгә җирдә булган гөлләр,*

*Сүнмәсенгә кояш нурлары.*

*Исәнмесез! Туганлаша илләр*

*Ярдәмләшеп яшәр өченгә,*

*Исәнмесез! Кояш нуры белән*

*Тормыш яме иңгән бу сүзгә!*

## ***Киек казлар китә...***

*Кыйгак-кыйгак...*
*киек казлар китә,*
*Киек казлар китә тезелеп.*
*Пилоткамны салып сәлам бирәм*
*Чын,*
*көнләшеп калам  сүрелеп.*
*-Дускайларым, хөр-ирекле кошлар,*
*Бишегем аша минем үтсәгез,*
*Сәламләгез әткәм-әнкәемне,*
*Сөйгәнемне*
*Ил солдатын якын күрегез:*
*Сәламләгез!*
*Ишетәсезме,әй канатлы дуслар.*
*Ишетәсезме солдат авазын?*
*Мин әйтергә телим йөрәгемнең*
*Сагыш утларында кайнавын...*
*Җиткерергә телим хезмәтемдә*
*Сынатмавым,*
*намус белән хезмәт иткәнем*
*Хат-хәбәрне дуслар-туганнардан*
*Һәрвакытта зарыгып көткәнем.*
*Сау булыгыз, һай, кайгысыз дуслар*
*Армый-талмый гына очыгыз*
*Аерылмагыз! Аерылу – кайгы*
*Уртак  малны күмәк тотыгыз:*
*чын күңелдән сөйли*

*дустыгыз...*
*Киләчәккә зур өметләр белән*
*Бергә-бергә очу-омтылу –*
*Олы бәхет!*
*... Ә аерылуда – кайгы-сагыш*
*Кара уйлар сазына йотылу...*

*1967 ел июль ае*

## *Уйлар сине эзли, Гөлем минем…*

*Яңгырады кискен күкрәү кебек*
*Өн качыргыч “Подъем” авазы*
*Атылып чыгып тышка күкрәк тутырып*
*Мин суладым таңгы һаваны.*
*Күзләремне киеребрәк ачып*
*Караштырам тирә-юнемне:*
*Нинди гүзәл дөнья! Күзләр алдашамы?*
*Төшме соң бу? Әллә өнемме?!*
*Якындагы каен сылулары*
*Алтынсыдан шәлләр ябынган.*
*Әйтерсең лә пешкән-моңсу кызлар*
*Карап тора көзнең таңында.*
*Әллә шунда ал таң иркәләүдән*
*Туган моңсу-серле хисләрем-*
*Каен гүзәлләре әкрен генә*
*Пышылдаша җылы иртәдә.*
*Таң нурлары,күбрәк назлагыз сез*
*Нурлар булып яусын сөюегез!*
*Каен кызыйларын әнә ничек*
*Җанландырган сезнең көлүегез.*
*Дөнья матур!*
*Мондый сихри таңны*
*Яшьлегемдә тәүге күрүем*
*Әллә ничек шушы таңга охшаш*
*Шикелле бит минем сөюем.*
*Әллә ничек, шушы көз таңында*
*Тиңлим аны каен кызына.*
*Әйе, аңа булган мәхәббәтем*
*Тәүге хисләр – кояш нуры ла!..*
*Көннәр үтә,ә мин һаман саен*
*Сөя төшәм,күбрәк янамын,*
*Тик һаман да җансыз каеннардай*
*Ул ...*
*Көтә күңел керсез җавабын.?!*

*Көтәм, тәүге мәхәббәтем минем,*
*Сизмисеңме йөрәк газабын?*
*Шул газаплы кайнар хисләрдән бит*
*Каеннарга болай каравым...*
*Сагыш уты җанны өткәнгә бит*
*Таңнар сихри...хисләремдә*
*юләр агым бар.*
*Диңгез кебек очсыз уйларымны*
*Алар һаман сиңа ялгыйлар!..*
*1967ел 1октябрь*

***Кайту.***
*Тәвәккәллек солдат юлчысы бит*
*Ә хәвефне солдат уйламый.*
*Шулай...*
*кояш кичкә авышканда*
*Бишегемә ...*
*авылыма таба юл алдым.*
*Яңа газик коштай оча гына,*
*Йөрәк кебек эшли моторы,*
*Изге хисләр кайный күңел тулып-*
*Тиздән күрәм туган якларны!*
*Бик-бик тиздән газиз әткәм-әнкәм,*
*Туганнарым тирән аптырап,*
*Ни көләргә,ни еларга белми*
*Төпчекләрен алыр каршылап.*
*Пилоткамны басыбрак киям,*
*Баса төшәм газга көчлерәк,*
*Юләр йөрәк ташкыннардай дәртен*
*Шулай күчерә.*
*Ялкынланган күзләр фара утын*
*Узып алны тели күрергә.*
*Уйлар инде!..*
*Уйлар өлгергәннәр*
*Туган йортка кайтып керергә.*
*...Менә алда утлар чагылып үтте*
*Һай, Бәзәкәм! Авылым, исәнме!*
*Бер күрергә синең улың кайта,*
*Тартты сиңа йөрәк хисләрем.*
*Саумы, авылым минем ,үзгәргәнсең,*
*Ничек якты,нурлы балкыйсың,*
*Ничек сине өзелеп сагынмассың,*
*Ничек сиңа очып кайтмассың?!!*
*-Сау гынамы, газизләрем минем*
*Әткәм-әнкәм...менә кайттым да*

*-Улым,улым...ничек? Кайттың да!*
*Сәер тойгы ача күрешү-сөенеч...*
*Әнкәемнең кайнар яшьләре,*
*Картлык баса төшкән әткәемнең*
*-Яхшы,улым,- диеп әйткәне.*
*Йөрәгемне кинәт йомышартты*
*Һәм беренче кат гомеремдә*
*Аерылудан соңгы күрешүнең*
*Олылыгын тойдым күңелемдә.*
*Һәм беренче кабат гомеремдә*
*Йөрәгемә әткәм-әнкәемнең*
*Бик-бик якынлыгын сөйләделәр*
*Күзләремә ихтыярсыз тулган яшьләрем.*
*...Өстәл башы кайнар сүзләр белән*
*Гел тынмаска гөрләп торасы*
*Тик солдатның вакыты бик кыска шул*
*Бүген монда...биш минуттан кайда буласын*
*Ходa белсен...*
*Саубуллашу...*
*тагын күз яшьләре,*
*Йөрәкләрнең әрнеп сызлавы,*
*Күз алдымнан ахры мәңге китмәс*
*Әнкәемнең мине соңгы кабат*
*Назлар өчен сузган куллары.*
*Йөрәгемнән – юк, беркайчан китмәс*
*Әткәй сүзе "Улым,югалма!"*
*...Кичерегез, газиз кешеләрем,*
*Сезне ахры салып кына киттем*
*Газапларга ,борчу, уйларга.*
*Кичерегез, дуслар! Сезне дә бит*
*Күрә алмадым, бигрәк ашыктым,*
*Тик зыян юк,бу һич кайгы түгел*
*Очрашырбыз!*
*Ил кояшы гына яктырсын*
*Һәм солдатлар гына сак торсын!!!*
*1967 ел, ноябрь.*

## ***Йөрәгемә берәү кабат үрли.***

*Нәфес дигән нәрсә миндә дә бар,*
*Юләр каннар ташый миндә дә.*
*Кызлар, кызлар...сансыз гөлләр алар*
*Тик мин өйрәнмәгән,*
*Өйрәнмәм дә инде*
*Һәркайсына*

*Йөрәк хисләремне сибәргә.*

***

*Сарман буйларында сылу кызлар*
*Чәчәк кебек нәфис сынлылар.*
*Йомшак кына сорадылар миннән:*
*-Син шагыйрьме, солдат?*
*Шигырьләрең матур ,җылылар...*
*Мин уңайсыз гына җавап бирдем:*
*-Юк, чибәрләр, шагыйрь түгел лә,*
*Тик тынгысыз юләр йөрәгемнән*
*Ярсу хисләр минем түгелә.*
*Шулар гына сезгә - бары шулар*
*Матур җырлар булып күренә...*
*Ә мин шатмын сезнең саф йөрәкләр*
*Тоя алгач хисем җылысын,*
*Гүзәл яклар, гөлләр кебек кызлар*
*Җырламыйча ничек чыдыйм соң?!*
*Серле генә карап елмайдылар,*
*Сорадылар көлеп үзләре:*
*-Әйтегезче, сезне өзелеп көткән*
*Кешең бармы – дустың, сөйгәнең...*
*Мин игътибар белән карап торам*
*Ни әйтергә, нәрсә дәшәргә?*
*Һәм шул вакыт күрәм - бер нәфис гөл*
*Күзләремә минем төбәлгән дә*
*Гүя тели минем,*
*йөрәгемә үтеп яшәргә...*
*-Исемегез ничек?.. Сорый үзе*
*Әллә сорый...әллә ... белмәдем*
*Күзләренә аның йотылдым да*
*Таныш сыйфатларны эзләдем.*
*Аныкыдай сылу-зифа буй-сын,*
*Тик күзләре генә сорылар,*
*Янып торган утлы,чиста күзләр*
*Нидер сөйли... әллә сорыйлар?!*
*Йөрәк купты...*
*Аныкыдай нәфис,*
*Аныкыдай сусыл иреннәр.*
*Тулып ташкан шушы саф иреннәр*
*Нидер сөйли... әллә көйлиләр?!*
*Артык дулкынлану җиңде мине,*
*Әллә ничек тел дә бәйләнде.*
*Шулчак миңа суза гүзәл кызый*
*Үзе кебек гөлләр бәйләме...*

*Күзләремә һаман туры карап*
*Әйтә:*
*-Әнвәр, кичер юләрне,*
*Минем сүзләр олы йөрәгеңә*
*Кайгы салыр диеп белмәдем,*
*Ал син,үтенәм ,Әнвәр, ул гөлләрне!*
*Алар сиңа диеп җыелган.*
*Ал чәчәкләр саф күңелемнән минем*
*Тик сиңа дип кенә сузылган.*
*Бу сүзләрдә, әйе, бернинди дә*
*Ясалмалылык югын йөрәгем*
*белән тойдым һәм бу кызга туды*
*Күңелемдә изге сүзләрем:*
*-Мин бик шатмын! Рәхмәт,Сарман гөле!*
*Сагыш-моңнар тулды күңелемдә.*
*Якты хисләр тудырдың син, гүзәл*
*Күңелең нурын миңа бүлдең дә.*
*Бәхет чаткысында сөендердең мине..*
*Кайдан гына пәйда булдың соң син?*
*Серле карап серле сөйләвең*
*Белмим, миңа ниләр вәгъдә итә*
*Сөйлим сиңа, сорыйм бүлмәвең.*
*Әйе,мин ярата белдем, мин яраттым*
*Ул мәхәббәт дигән газапны.*
*Кичерә идем – бәхетле күк идем*
*Дөнья матур иде шул чаклы.*
*Тик бер кичне...*
*бары да асты-өскә*
*Килеп бетте – аңа ни булды?*
*Белмим, ул очынып мине читкә куды*
*Шул минуттан*
*Уртак хисләр,  беренче зур хисләр*
*Көзге гөлләр кебек корыды.*
*Аңламадым мондый кискенлекне*
*Ул ни уйлап болай эшләде?!*
*Белмим.*
*Ләкин элеккечә*
*Яшәделәр миндә, һаман саен*
*Сүрелмәде сөю хисләрем.*
*Мин җавапсыз сөю уты белән*
*Һаман яндым!*
*Хыялымда аның янында,*
*Аның белән идем...тоймый идем*
*Аннан башкаларның барын да.*
*Йөрәгемдә тик ул гына иде*

*Башкаларны йөрәк күрмәде*
*Ә ул...*
*ул ни уйлагандыр*
*Тик ул һаман җавап бирмәде...*
*Һәм хәзер дә җавапсыз*
*ут яна...*
*Син соң менә кайдан пәйда булдың*
*Син кузгаттың кабат йөрәкне*
*Күзләр аша йөрәгемә карап*
*Яшерен хисләремне сөйләттең...*
- *Мин баш иям мондый мәхәббәткә,*
*Мин бөтенләй сабый икәнмен.*
*Мондый кешеләрне тәүге күрәм,*
*Тәүге тыңлыйм шундый йөрәкне.*
*Кичер, Әнвәр! Тик ,син, әйтче,зинһар*
*Мәхәббәтең булгач җавапсыз*
*Ул тамырсыз гөлдәй корымасмы,*
*Кошлар да бит*
*оча алмыйлар пар-пар канатсыз?*
*Бер-береңдә яши алсаң гына*
*Тормыш тулы, йөрәк ярсулы...*
*Сез аңларсыз мине...мин башкага*
*Сөйли алмыйм*
*телем бәйли*
*хисме, ташкынмы?..*
*Сез аңларга тиеш кеше мине...*
*-Я, хуш, Әнвәр – аңла!*
*- Тукта – китмә, Клара.*
*Күзләренә аның йотылдым*
*Һәм гөнаһсыз саф, эчкерсез йөрәк*
*Аһәңнәрен йөрәк укыды.*
- *Очрашуга кадәр, Клара! Иртәгәсен кичен*
- *Күл буенда көт мине, яме?*
- *Әйе..*

*(Тәрбия һәм тормыш аны адаштырды.1971 ел)*

***

*Сине эзлим.*
*Хат-хәбәрләр килә дус-ишләрдән*
*“Ул чуала фәлән белән” дип.*
*Уйлар белән һаман аның белән*
*Йөрәк һаман аның белән бит...*
*Нишлим, дуслар?!*
*Күңелемнән аны*
*Куа алмыйм, күңел күзләрем*

*Сайлый-сайлый эзләгәннән соң бит*
*Шул кызыйга барып төпләнде.*
*Аның дымлы зәңгәр күзкәйләрен*
*Серле күзкәйләрен оныту*
*Мөмкин мени?.. Аны гына теләп*
*Янган йөрәгемне*
*Ул юк инде диеп юату?!*
*Мөмкин түгел!*
*Тормыш юлы тулы гөлләр белән,*
*Мин аларын күрәм – онытам*
*Тик шул гөлне көннәр үткән саен*
*Һаман саен ныграк уйлата.*
*Хыялларда аның белән рәттән*
*Әллә ниләр эшләп йөрим дә,*
*Ул юк инде! Бөтенләе белән*
*Ул бирелгән инде бүтәнгә...*

*******

*Мең тугыз йөз дә алтмыш җиденче ел,*
*Унберенче декабрь, кичке тугызда утызда*
*Мин сүз бирәм!*
*Чын һәм якын дустым*
*Тимерхан дустыма сүз бирәм:*
*Тормыштагы авыр кайгы-зарны*
*Күтәрергә күмәк көч белән!*
*Шатлыкларда бергә сөенешергә,*
*Җиңүләрдә бергә көләргә.*
*Аның шатлык мине сөендерсен,*
*Үз шатлыгым уртак бүләргә.*
*Мин сүз бирәм: мәңге хыянәтсез*
*Саф йөрәкле якын кешемә:*
*-Сине яклар өчен,саклар өчен*
*Йөрәгемнең соңгы көчен дә*
*Кызганмаска!*
*Тормыш тапмас безне бөгәр көчне,*
*Безне егар көчләр табылмас!*
*Солдат чакта сиңа биргән сүзем*
*Соңгы минуткача алынмас!*
*(1967 ел 10 декабрь)*

*******

*Төрекмәнстан...*
*якты кояш иле!*

*Нур балкышы, кошлар сайравы.*
*Барысы рәхәт, ләкин бернәрсә дә*
*Алыштырмас Иделем ярларын.*
*Гөлчәчәкләр үскән, Төрекмәнстан,*
*Синең гүзәллекнең*
*Баш очыннан туган якка карап,*
*Тоям гүзәллекне.*
*Хурламыйм мин якты, гөлләр иле –*
*Төрекмәнстан, гөнаһ хурлау сине.*
*Оҗмахлардан качып кайтырмын мин*
*Зурлап, сагынып туган җиркәемне.*
*Йөрәк белән, тамырларда кайнар*
*Тибеш белән аккан каным да.*
*Җаным белән, бар барлыгым белән*
*Аерылмагач туган ягымнан.*
*Нигә шунда барыр юлларымда*
*Җәннәт ишекләре ачылмый.*
*Мин һаман да*
*канатланып-очып*
*Туган туфрагыма кайтырмын!*
*Кичер мине, гүзәл Төрекмәнстан,*
*Мин яшәмим синдә, тик янам*
*Дәрьяларың бик мәкерле синең,*
*Иделкәем минем – үз анам!!!*

## “Кама” колхозы сыер савучыларына поэтик характеристика.

***Яшь килен Фәхерлебанәткә.***
*Тормышка да бик тиз кердең,*
*Эштә дә җитез – ут бул!*
*“Яшь килен” сүзен халыкның*
*Һәрвакыт акларлык бул!*

***Уңган савымчы Нажия апасына.***
*Берәүләр кирә дә чыга*
*Ә син – юк, андый түгел.*
*Эшеңә саф уйлар белән*
*Береккән синең күңел.*

***Озын акчалар эзләүче Хәтимәгә.***
*-Төрле җирдә эшләү, чынлап,*
*Чегәннәр хәленә тиң,-*
*Дигәнсеңдер, канатланып*
*Фермага килдең бит син.*

*Бу эшең синең киләчәк*
*Юлыңны нурга төрер.*
*Тырышлык, алдынгы хезмәт*
*Шатлыклар алып килер.*

***Иң гади эш апасы Хәтирәгә.***

*Бүгенгәчә тормыш юлың*
*Үтте маллар арасында.*
*Син аларны һәрвакытта*
*Яраттың.*
*Ярадасың да!*
*Малларың да яраталар,*
*Сөя сине кешеләр дә*
*Киләчәкнең нигезе сез.*

***Алдынгы савымчы Нәдитҗәгә.***

*Таң атканда авылыбызга*
*Әтәчләр хәбәр сала.*
*Шулчакта син ашыгасың*
*Ферма ягына таба.*
*Һәр яңа таңда сине бит*
*Яңа эш – уңыш көтә.*
*Әйтәсең : "Авылда гөрләп*
*Торуга ниләр җитә?!"*

***Олы җанлы уңган савымчы Фәткыяга.***

*-Үз эшеңә карашыңны*
*Әйтче,- дисәләр аңа,*
*-Сөям,- ди ул,-бик яратам*
*Калганын үзең аңла.*
*Аңлашыла...*
*һәркем аңлый*
*Бездә эш яратканны*
*Әйтәләр аның хакында*
*-Шәп кеше, олы җанлы!*

***Авыл кызы йомшак җанлы Саимәгә.***

*-Мин яратам туган җирнең*
*Кырларын, малкайларын.*
*Алар янында булганда*
*Борчусыз җанкайларым.*
*Әйе, сыерлар янында*
*Ул һәрчак көләч йөзле.*

*Тагын ни кирәк дөньяда...*
*Бу бит бәхетнең үзе!.*

***Авылның беренче савымчысы,почет тактасы герое Нажиягә.***
*Тормыш аңа кече яшьтән*
*Күтәртте ирләр йөген.*
*Почет тактасыннан карыйк*
*Кемлеген аның бүген.*
*Күп сөйләшмәс, тик эшләгән*
*Литр саннары гына*
*-Мин алда!- дип гүя аның*
*Чын йөзен чагылдыра.*

***Яңа савымчыга.***
*Үткән тормыш сукмагында*
*сынатмадың*
*сынатма да.*
*Фермада да нәкъ шулай бул*
*тырыш*
*атыл алга таба!*

***Яшь кыз Рәфинәгә.***
*-Гөлдәй чагың,кит шәһәргә,*
*Авылда сулып ятма!?*
*Дисәләр, ул җавап бирә:*
*-Яшьлегем чәчәк ата!*
*Шәһәр диләр...Туган җирне*
*Буламы аңа тиңләп?!*
*Тиңсез бәхет туган җирдә*
*Яшәү хезмәттә тирләп!*

***Намуслы савымчы Нурнисага.***
*Беркайчан да акырмый да*
*“Минме,мин!- дип шапырмый да.*
*Акыллы ла*
*доярка кыз Нурнисабыз*
*Эшләгәне зур көч куеп*
*Яулап алса алдынгылык*
*матурлана,*
*алсулана Нурнисабыз!*

***Башлангыч савымчы Нәсимәгә.***
*Каһәр язмыш яшьлегеңнән*
*Итте сине ятимә.*

*Горур булдың, кыенлыкка*
*Баш имәдең һәм имә!*
*Ул һәрвакыт шулай авыр*
*Яңа эш башлангычы.*
*Ләкин синдә өметләр зур*
*Акларсың ышанычны.*

***Халык яраткан кыз Хәлимә савымчыга.***
*-Инсафлы ул һәм тыйнак та,-*
*Дия халык аның хакта.*
*Халык сүзе һәрвакытта*
*Нигезләнә бит фактка.*
*Сөт нормасын тутырулар,*
*Арттырулар бер мәсьәлә.*
*Ә халыкның сине сөеп*
*Олылавы – зур мәртәбә.*

***Мәхәббәт бер генә.***
*Кочарга талпына йөрәгең*
*Иректә хөр үскән гөлләрне.*
*Күрмисең,белмисең бакчаңда*
*Үзеңнең гөлләрең шиңгәнне.*
*Шиңделәр бакчаңда гөлләрең*
*Күрмичә иркәләү-назлауны.*
*Мәхәббәт бер генә, нәфсеңә*
*Бәйләмә һәр килгән язларны.*
*(Тәнкыйтьче "Яңа Кама" һәм үзем. 1967 ел.)*

***Кыш.***

*Дөнья ап – ак . Агачларга*

*Бәсләр кунган.*

*Суык агай тәрәзләргә*

*Сүрәт уйган.*

*Кыекларда күгәрченнәр*

*Йон күпертеп*

*Утыралар муеннарын*

*Эчкә кертеп.*

*Чыпчык – чытлык посып ята*

*Саламлыкта .*

*Салкын ага киртә куя*

*Шаянлыкка.*
*Кешеләрнең сулышыннан*
*Пар бөркелә ,*
*Йөри алар һәммәсе дә*
*Җәһәт кенә.*
*Колак салсаң - әллә кайда*
*Йөргән кеше*
*Шыгырт – шыгырт яныңнан ук*
*Үтә төсле.*
*Вакыт-вакыт бүрәнәләр*
*Чатнап куя,*
*Әйтерсең, кыш кылган эшен*
*Раслап куя.*
*Алсу йөзле шат күңелле*
*Шук балалар*
*“Куян атып” карга батып*
*Тау шуалар.*
*Боз өстендә арлы-бирле*
*Йөгерешеп*
*Малай-шалай шар уйната*
*Янып-пешеп.*
*Салкын булсын, үлми кеше*
*Аңа карап.*
*Тик үз йөрәк салкыныңнан*
*Өшү харап.*
*(“Ялкын”да конкурста катнашкан шигырь.1965 ел.)*

## ***Армиядән соң***

***Башкаемны иям.***

*Зәңгәр күзләреңә бу кадәрле*
*Ялкын кайдан туган?*
*Карашыңа кеше сүзләренә*
*Сыймас назлар сыйган...*
*Шулкадәрле төбәп карамачы*

*Уңайсызлык тоям...*

*Олы сөю янган күзләргә мин*

*Лаек түгел сыман...*

*Яннарыма килеп баскан чакта*

*Кояш рәттән кебек*

*Шуңадыр ла кыен иркәләргә*

*Чәчләреңнән үбеп...*

*Карашларың белән син минеке*

*Әйтмәсәң дә сизәм...*

*Уйларымда синең күкрәгеңә*

*Башкаемны иям!..*

*1970 елның 9нчы ноябрь киче.*

***

*Укыйм да, язам да,*
*Уйлыйм да моңаям;*
*Бик кирәк кеше идем,*
*Бердәнбер якын кеше идем*
*мин аңа ...*
*Мин күрдем сөюен,*
*Яратып йөрүен*
*Мин күрдем ул кызда*
*мәхәббәт газабын!..*
*...Кызгандым мин аны*
*Үз итеп кызгандым.*
*Тик чынлап ярата алмадым,*
*алмадым.*
*“Киңәшчем булмады...*
*Ә йөрәк сызланды...*
*Яныма килмәдең...белмәдең,*
*Ник минем газапны?*
*Күземә сарышкан*
*Сагышны бөтенләй күрмәдең?”*
*Бу соңгы сүзләре –*
*Бер ялгыз ул кызның...*
*Бу сүзләр өздереп әйтелде...*
*Акылым-уйларым кыйныйлар йөрәкне:*
*“Я, кем син?*
*Әйт инде? Әйт инде?!.”*
*Йөрәктә ут түгел – кызгану сагышы...*

*Көчле һәм рәхимсез*
*бу тормыш агышы...*

## ***Көз.***

*Асфальт юлда сары яфраклар,*
*...Саргаешкан каен кызлары;*
*Үзәкләргә үтеп искән җилдә*
*Ишетелә кебек моңнары.*
*Җыелышып йөри киек кошлар,*
*Кыр казлары китә тезелеп.*
*...Алсуланып пешкән соңгы алма*
*Сабагыннан төшә өзелеп.*
*Табигатьтән гүзәл төсләр ача.*
*Ә күңелдә моңаюлар арта,*
*Гөл үстергән кырлар бушый,тына*
*Яшь күңелдә ташый уйлар гына...*
*1970 ел 6 октябрь.*

## ***20 нче сентябрь***

*Йолдызларга кара кайгы төште*
*Ай да посты болыт читенә*
*Көз аеның егерменче төне*
*Авыр булды минем өчен дә.*
*Ул төнне бит янар йолдызларга*
*Нур өстәрлек иде хисләрем!*
*Тик син...*
*Шундый гүзәл шигъри кичкә*
*Тик тупаслык кына өстәдең...*

*******

*Мин кем икән...*
*-Син кем , – диләр*
*Белмим!*
*Мин шагыйрь дә*
*Мин шофер да*
*түгел*
*Мастер да.*
*Тик мин һәрчак тик үземчә хисле,*
*Кешенеке түгел - акыл да.*
*Димәк –*
*Үзем белән үзем, асылда!*

## ***Сүнмәс гөлләр.***

*(Р-гә)*

*Беләм чая!*
*Синең уйларыңда*
*Мин уйланмас*
*кеше һаман да.*
*Үткен-мескен, астыртын да диген,*
*Хет әллә кем диеп яманла.*
*Минем хакта тузга язмаганны*
*Сөйләсәң дә төрле кешегә,*
*Исемемне, бәлки, җиргә таптап*
*Характерым алып көлкегә*
*Нишләсәң дә...*
*Керле уйлар белән*
*Җырларымда янган хисләрне*
*Тупас аңлап,зинһар, имгәтмә?!!*
*Җырлар алар – күңелдәге гөлләр*
*Тамырлары – янган йөрәктә.*
*Ә йөрәккә төкерү кирәкмәс!..*

*1970 ел 17 октябрь.*

## ***Кемдә ни соң?***

*(Үземә үзем)*

*Горурлык ул гүзәл,күркәм сыйфат*
*Тик аның да була бер чиге.*
*Әнә шушы чикне узса кеше,*
*кеше түгел*
*Дуңгыз була каһәр төшкере.*
*Кемдә икән гаеп?*
*Нигә икән*
*Хет сөюдә "дуңгыз" булырга.*
*Горурлык ул,әйе, гүзәл сыйфат.*
*Әүвәл кирәк кеше булырга*
*Аннан инде бәлки горурлык һәм*
*Сөю юлдаш булыр юлыңда.*

## ***Йолдызлар атыла.***

*Йолдызлы бер төндә кыз бала*
*Яшьлеген сөйләде моңаеп.*
*Тын гына йоклаган яфраклар*
*Сискәнеп,калтырап уянды...*
*Бик яшьли югалткан әнкәсен*
*Ул тирән сагышта юксына*

*...Бу төндә*
*Иң нечкә*
*хисләрем иркендә*
*Утырам уйланып шул кызны.*
*Ай да бик пошынган, моңайган*
*Күңелең ярасын абайлап*
*...Йолдызлар атыла...һәм сүнә,*
*Күңелне тагын да яралап.*

*1970 ел 18 октябрь*

## ***Бәхет***

*- Янып – көеп кая ашыгырга,*

*Картайгач та кирәк көч, - диләр*

*Акмый яткан күлләр исләнәләр*

*Без онытмыйк шуны, кешеләр:*

*Бәхет яумый күктән – көтмә аны,*

*Шытып чыкмый кыргый гөл кебек.*

*Гомереңнең тәүге бер көнендә*

*Уй – хыяллар аша күңелеңдә*

*Бөреләнә башлый иң элек.*

*Сайладыңмы очучылык эшен*

*Оч син Айга!*

*Юл ал Марска!*

*Ватан кушса*

*Оч син ут эченә*

*Олы эшең керсен тарихка.*

*Сайладыңмы игенчелек эшен –*

*Басуларның бул син хуҗасы!*

*Туган илең сине “Улым” – дисен*

*Халкың сине зурлап җырласын.*

*-Ник янасың? Кая ашыгасың?*

*Картайгач та кирәк көч диләр*

*Күктән төшмәс бәхет - җирдә ятмас*

*Онытмыйк без шуны, кешеләр!*

*(“Яңа Кама”да басылган шигырь, 1970ел)*

## ***Сизмисеңме иркәм.***
*Әллә язның зәңгәр чәчәгеннән*
*Зәңгәрлекләр күчкән күзеңә;*
*Исемнәрең әллә Чулпан микән,*
*Таң йолдызы нуры йөзеңдә.*
*Чишмәләрнең көмеш тавышлары*
*Сафлыклары синдә сизелә.*
*Тургайлардыр,ахры, гүзәл җырлар*
*Салып киткән синең күңелеңә.*
*Толымнарың тибрәндереп үткән*
*Җилләрдән дә куям көнләшеп*
*Сизмисеңме, иркәм,күзең төсле*
*Гөлләр белән йөрим сөйләшеп.*

## ***Ник алай?***
*Яз җилләре бу ел бигрәк назлы*
*Яңа җырлар суза сандугач,*
*Сандугачлар белән канатланам*
*Йөрәкләрдә ялкын кабынгач...*
*Җылы куллар итеп сибә кояш*
*Мәхәббәтен нәфис гөлләргә!*
*Ирексездән сине уйлый күңел*
*Шул гөлләрнең йөзен күргәндә.*
*Кояш көнләшерлек карашларың*
*Нигә алай сирпеп үтәсең?!*
*Үтәсең дә үзең белән бергә*
*Уйларымны алып китәсең...*

*1970 елның марты.*

## ***Сагыну җыры.***
*Икәү генә йөргән сукмакларда*
*Суынмаган кебек эзең дә.*
*Көлә-көлә, шаян сүзләр сөйләп*
*Син килерсең кебек бүген дә.*
*Икәү генә белгән аланнарны*
*Берялгызым иңлим уйланып,*
*Баш иäләр миңа ак чәчәкләр*
*Уйларымны тоеп, моңаеп.*
*Икәү генә белгән тыныч күлдә*
*Тынычлыгы качкан дулкыннар*
*Сорый кебек миннән килгән саен:*
*-Хәбәр бармы якын дустыңнан?*
*Без ясаган җылы ояларда*
*Сыерчыклар бала үстерде.*

*Канатларын җилпи-җилпи алар*
*Сине сагынып җырлый шикелле.*
*1969 ел.Чарджау.*

***Яңа ел көткәндә.***
*Вакытның ярсу чабышы*
*Җилләрне узып китә,*
*Күңелләргә җыр кабызып*
*Яңа ел түргә үтә.*
*Кыш бабай бүләкләр бирә*
*Чыршы әйләнәсендә;*
*Әллә ул бәхет бүләме*
*Тигезләп һәммәсенә.*
*Сабыйдай эчкерсез сафлык*
*Елмаюларда тоям,*
*Талпынсам кар бөртегедәй*
*Очып китәрмен сыман!.*
*1970 ел 28 декабрь.*

***Кышкы урманда.***
*Бик сак кына атлыйм*
*Урман йоклый*
*Тәмле төшләр күреп*
*Җырлар идем*
*Зирекләрнең төшен*
*Бүләрмендер кебек.*
*Ап-ак бүрек кигән чыршыларны*
*Сөеп карап торам*
*Бу яшеллек шаһын нинди көчләр*
*Бизәндереп куйган?!*
*Озын чуклы ак шәленә төренеп*
*Йоклый каен кызы.*
*...Кышкы урман тып-тын...*
*Җырлар идем*
*Иң-иң гүзәл җырны!*
*1970 ел.*

***Әйтче,зинһар.***
*Ник син шулай уйчан, әйтче,зинһар,*
*Ник син болай боек?!*
*Гөлләр әнә башын түбән игән*
*Моңаюың тоеп...*
*Син коенган тыныч күлнең әнә*
*Тынычлыгы качкан...*

*Мин дә янам, күрер идең аны*
*Күзләремә баксаң?!*
*Әйтче, зинһар, эчке газапларың*
*Әллә яратудан?!*
*...Аh! Карама шулай серле итеп –*
*Көл итәрсең сыман.*
*1970 ел.*

## ***Төнге уйлар.***

*Авыл йоклый караңгыга чумып*
*Йолдызлар да сүнгән.*
*Ник йокламый йөрәк,*
*Аңа нинди*
*Авыр борчу килгән?!*
*Елмаеп та куям нидер уйлап,*
*Шундук моңаям да,*
*Мин сабыйга охшыйм, хыялый бер*
*Сине уйлаганда.*
*Шыпырт кына искән төнге җилләр*
*Нидер сөйләр кебек.*
*Йолдызым да балкып кабыныр да*
*Нурын сибәр кебек.*
*Шушы төндәй өнсез түгел күңел –*
*Өмет сүрелмәгән,*
*Тормыш чүбе белән йөрәктәге*
*Ялкын күмелмәгән.*
*Авыл йоклый авыр төшләр күреп,*
*Миннән йокы киткән.*
*Өмет белән, изге хисләр белән*
*Туар көнне көтәм.*
*1971 ел 26 сентябрь.*

## ***Төнге уйлар.***

*Очрадың да тагын исәнләштең –*
*Ялкынга җил өрдең.*
*Белмәдең дә, тик туасы көнем*
*Тынычлыгын бүлдең.*
*Син йөгереп җитеп узып киттең*
*Бәлки, нидер уйлап.*
*Ә мин калдым...йөрәгемнең соңгы*
*Горурлыгын җыйнап.*
*Хат язышкан кешеләр сизенсәләр*
*Тагын әйбәт түгел.*
*Ә мин уйлыйм үзем шул минутта*
*"Буй җиткәнгә үрел!"*
*Йолдызларга җитеп булмыйдыр ла,*

*Дисә дияр кеше.*
*Авыл гына җиңә алса икән*
*Йөрәктәге хисне!.*
*27сентябрь 1971 ел.*

## ***Йокысыз төн.***

*Бер күз сирпеп алдың – шул да җиткән,*
*Күпме кирәк юләр күңелгә,*
*Шул да җиткән... туар көнгә кабат*
*Синең белән барып керергә.*
*Шул да җиткән...йөз өметле уйлап*
*Мең күзаллар өчен киресен.*
*Сөя белмәсен дә икән кеше!*
*Башкалардан гына сөелсен...*
*Акыл, акыл! Мондый сүзләреңне*
*Бу йөрәккә нигә сөйләргә!?*
*Кеше бөек! Кеше матур! Горур!*
*Онытылып сөя белгәндә.*
*30 сентябрь 1971 ел.*

*****

*Ике ел күңелдә йөртеп...*
*Салкын ачы бураннарда*
*Яланнарга, кырга чыгам.*
*Бушанырга, йөрәгемне*
*Коткарырга борчулардан.*
*Чеметтереп яңакларны*
*“Өшетәм” дип яный буран.*
*Тик үҗәтлек кенә арта:*
*-Кеше янар өчен туган!*
*Урман тынлыгына чумып*
*Тынгы тапмак булам җанга тынлыкта*
*Серле, көчлерәк телим булуын янда.*
*Ак каенның толымнары*
*Итәгенә сибелеп төшкән...*
*Гел ул инде!!!*
*Эх, син йөрәк, сүнмәс бер уй булыр икән.*

*****

*Үзем шундыйдыр ла...*
*Син тиң тоелсаң да*
*Мин тиң түгел төсле!,,*
*Һич буйсынмый йөрәк бу уйларга,*
*Үземнеке көчле!*
*4 январь 1972 ел.*

***Кабат яз килә.***
*Көмеш айны, якты олдызларны*
*Кара болыт күмгән.*
*Йөрәктәге саф уйларым белән*
*Кайтам синең эздән.*
*Көннәр түгел инде, айлар уза*
*Һаман сине уйлап.*
*Һаман йөрим күңел газапларын*
*Җырлар итеп җыйнап.*
*Син дә үзең, мин дә үзем генә*
*Ни соң араларда?*
*Син бит доктор – үзең яраладың*
*Килче дәваларга!*

***Яз җыры.***
*Җир йөзендә гөрләвекләр җыры,*
*Һавалардан сибелә тургай моңы,*
*Ак каеннар әнә, бөре ача,*
*Урамнарда шат көлүләр арта.*
*Һай, яз җиле, бигрәк шаян инде,*
*Яшь кызларның итәкләрен ача,*
*Карны ертып умырзая калка,*
*Җиргә,дуслар, матурлыклар кайта,*
*Эх, җырлыйсы иде шул хакта!*
*8 апрель 1972 ел.*

***Көзге уйлар.***
*Авазлары күкне моңга күмгән,*
*Кошлар китә...*
*туган җирләрдән;*
*Һай, бу туган җирдән аерылулар*
*Мирас булып калган кемнәрдән?!*
*Япь-яшь имәннәрнең яфракларын*
*Җилләр йолкып илгә тарата...*
*Яфраклардай туган җирләреннән*
*Аерылганны тормыш саргайта.*
*Киткәннәрне туган туфрагыннан*
*Кызганам мин...авыр күңелгә...*
*Тик мин горур һәм шат, күзем ачкан*
*Аунап үскән туган җиремдә!*
*2 ноябрь 1972 ел.*

***Исәнмесез!***

*Заманыбыз ярсу чабыш безнең,*
*Эшләребез зур да , көчле дә;*
*Ашыгабыз...*
*юкмы вакытыбыз*
*Исәнләшеп узар өчен дә?!.*
*Исәнмесез!*
*Вакыт бүләме бу?*
*Каршылыкмы бу сүз кешегә?!*
*Саф күңелдән дуслар-туганнарга*
*Сәлам бирик зурга-кечегә!*
*Исәнмесез!*
*Бу җир тынычлыгы, дуслык хисе,*
*Туар көн яме!*
*Нинди шатлык,җирнең балалары*
*Күбрәк сөйсә шундый сүзләрне!!!*
*8 ноябрь 1973 ел.*

***Беренче кар ява.***

*Зәңгәр киңлекләрдән ак бөртекләр*
*Салмак кына җиргә сибелә.*
*Беренче кар ява,*
*Сулап туймас һава,*
*Бәйрәм бүген туган җиремә!*
*Туып-үскән җирем,һай,бизәнгән бүген*
*Гүя,буйга җиткән кыз бала.*
*Ихлас хискә чумып,иңнәрендә*
*Туй күлмәге тоеп елмая.*
*Туган җирем!*
*Мин гашыйкмын сиңа,*
*Тиңдәшсез лә синең сафлыгың!*
*Шул сафлыгың җырларыма күчә,*
*Күкрәгемә сыймый шатлыгым.*

***Эшем-сөенечем.***

*Таң иртәме, үзем иртәрәкме,*
*Таң туганчы ашыгам эшемә.*
*Хезмәттәшләр белән туган илгә*
*Үземнән дә өлеш кертергә.*
*Кумәк эштә ..............................*
*Киләчәген күрәм бүгеннән,*
*Күңел яраткан эшне, яшәү ямен*
*Биргән илгә рәхмәт белдерәм!*
*Җаным сөйгән эшем әйди мине*

*Ашыктыра һәрбер иртәсен,*
*Туган илгә кичәгедән күбрәк*
*Килә бүген өлеш кертәсем.*

***Сөенечем.***
*Әллә үзем, әллә эшем шулай*
*Әйдәп тора һәрбер иртәсен.*
*Илгә минем кичәгедән күбрәк*
*Килә бүген өлеш кертәсем.*
*Күмәк эштә күңел җыр яңарта-*
*Иртәгесен тоеп-сизенеп;*
*Җирдә яшәвемнең яме арта*
*Туя алмыйм шуңа сөенеп!*
*26 декабрь 1974 ел.*

***Изге бабай.***
*Таң беленә җиргә ямь өстәргә,*
*Бабай таңнан алда кузгалган.*
*Басма көйли инеш түренә ул*
*Олы юлга туры чыгарга.*
*Тынгысыз җан,чирәм баш төрткәнче*
*Чишмәләрне барлый-тазарта.*
*Чишмә суы кебек,  һәрбер өйдә*
*Изге, диләр аны бу якта.*
*Чишмәләргә тезелеп кызлар килә*
*Басмалардан үтә егетләр,*
*-Яшьтәшләрем!-дип шул яшьләрне*
*Яши бабай инде электән.*
*Яшь санын да әллә оныткан ул,*
*Унсигездә һәрчак күңеле*
*Саннар гына үлчи аламы соң*
*Күңелләргә күчкән............................*
*Февраль 1976 ел.*

***Мин октябрят.***
*Мәктәптән ул очып кайтып килде*
*Шатлык ташып чыккан йөзенә:*
*-Әти,-ди ул- безнең бәйрәм көне*
*Мин октябрят булдым бүгеннән.*
*Ленин бабай төшкән значокны*
*Укытучы апам кадады.*
*Гел бишлегә генә укы,диде*
*Хөрмәт итсәң Ленин бабаңны.*
*Укыр идем дә мин,укытучым*
*Кайчакларда дүртле куймаса,*
*Гел бишлене генә алыр идем*

*Башка төрле билге булмаса.*